ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ШАШЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

НОВОШАШИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Новые Шаши. Тел. 3-23-23

№1 17 март 2025 ел.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгының 2016 елның 15 декабрендәге 4 номерлы карары белән расланган «Яңа Шашы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль - хосусый партнерлык турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы, 2016 елның 3 июлендәге 360-ФЗномерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы, 2024 елның 8 августындагы 302-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» гы Федераль законнар, прокурорның 2025 елның 31 гыйнварендәге №02-08-02-2025/Прдп 34-25 протесты нигезендә, карар бирәм:

1. Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгының 2016 елның 15 декабрендә 4 номерлы карары белән расланган «Яңа Шашы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль-хосусый партнерлык турындагы нигезләмәгә (11.06.2021 ел, №3; 19.05.2022 ел, №1 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1. 2 өлешнең 5 пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:**

"5) килешү объектын эксплуатацияләү - килешү объектын килешүдә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру, товарлар җитештерү, эшләр башкару, килешү билгеләгән тәртиптә һәм шартларда хезмәт күрсәтү максатларында файдалану»;

**1.2. 7 өлешнең 6 пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:**

"6) каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру, медицина калдыкларын җыю, файдалану, зарарсызландыру, урнаштыру, саклау, транспортировкалау, исәпкә алу һәм утильләштерү гамәлгә ашырыла торган объектлар";

**1.3. 8 өлешнең 8 пунктындагы 3 абзацын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:**

"-хосусый партнер тарафыннан килешү объектын төзү һәм (яисә) реконструкцияләү (алга таба шулай ук-төзү). «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон максатларында килешү объектын реконструкцияләүгә аны яңа технологияләр кертү, җитештерүне механикалаштыру һәм автоматлаштыру, мораль яктан искергән һәм физик яктан таушалган яңа җиһазларны модернизацияләү һәм алмаштыру, килешү объектының яисә аның аерым өлешләренең технологик яисә функциональ билгеләнешен үзгәртү нигезендә яңадан урнаштыру чаралары, объектның

характеристикасын һәм эксплуатация үзенчәлекләрен яхшырту буенча башка чаралар керә;»;

**1.4. 8 өлешнең 8 пунктындагы 6 абзацын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:**

“-«Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында «2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 4.2 өлешендә каралган дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешү объектын реконструкцияләү очрагыннан тыш, килешү объектына хосусый партнерның әлеге Федераль закон нигезендә килешү объектына милек хокукы барлыкка килү;” ;

**1.5. 8 өлешнең 8 пунктындагы 10 абзацны түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:**

“ - «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясы нигезендә килешү объектының хосусый партнеры тарафыннан төзелүне өлешчә финанслауны тәэмин итү, шулай ук аны эксплуатацияләүне һәм (яисә) техник хезмәт күрсәтүне финанслау (алга таба - гавами партнерның финанс катнашуы);”;

**1.6. 8 өлешнең 8 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:**

"- хосусый партнер килешү объектына техник хезмәт күрсәтүне генә башкарса, килешү объектын эксплуатацияләүне гавами партнер тарафыннан тәэмин итү.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында: http://atnya.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Яңа Шашы авыл җирлеге
башлыгы: Сабирҗанов М.С.